РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Алан-Бексер, ул.Центральная, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**19 май 2020 ел** **№ 217**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 18 ноябрендәгәге 194 нчы номерлы «Җир салымы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «җир салымы турында " 18.11.2019 ел, № 194 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 5 пунктта. "салым түләүче-оешмалар" сүзләрен төшереп калдырырга»;

2) 5.1 һәм 5.2 пунктларын төшереп калдырырга»;

3) 7.1 пунктының 4 абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Ташламаны бирү өчен нигез булып Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы яисә сугышта катнашучы таныклыгы, күрсәтелгән ташламаны алу хокукын раслаучы башка тиешле документлар тора»

4) 3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.1.1 пункты белән тулыландырырга:

«3.1.1. Салым түләү салым түләүчеләр тарафыннан җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча башкарыла.

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал тәмамланганнан соң, узган хисап чорыннан соң килгән икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталындагы рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. 3.1.1 пунктының икенче абзацы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башлыгы З.Р.Гарифуллина